Рина Асылбаева
Болытка хать

Рина Асылбаева

Болытка хат

Казан Татарстан китап нәшрияты 1991

БОЛЫТКА ХАТ

Исәнме, болыт, саумы?!
Нишләп яңгыр яумый?
Яудыр яңгырны, яме?
Беләсеңме, бу җәйне
Мин зу-у-р үсәргә телим.
Сәлам белән:
Хәлим.

«ҚамАЗ» БЕЛӘН АЛМАЗ

Күзгедәй асфальт буйлап
Чаба өр-яңа «КамАЗ».
Әтисе белән «КамАЗ»га
Утырып кайта Алмаз.

Сирпелеп калган өйләргә
Карый да уйлый Алмаз:
— Әллә инде кояштан да
Тиз бара безнең «КамАЗ»?

Ләкин кояш артка калмый
Һәм чапмый ул алга да.
«КамАЗ» белән бергә бару
Рәхәт, ахры, аңа да.

Йөгереп өйгә керү белән
Алмаз шатланып әйтте:
— Әнием, безнең «КамАЗ»ны
Кояш озатып кайтты.

АЙДАР

Қызынабыз. Тәннәребез
Гәрәбә төсле була.
Тик Айдар гына
кызынмый.
Дерелдәп ята суда.

— Қарагыз,— ди,—
сез инешкә,
Әнә ничек тиз ага...
Қызынып яткан арада
Су агып бетеп бара.

ЯРАТАЛАР

Җирәне дә, йөнтәсе дә,
Баллысы да, гөрҗәсе дә
Яраталар яңгырны.
Бу арада көннәр эссе,
Көннәр эссе —
Гөмбә үсми...
Их, чиләкләп яугыры!

...Көтмәгәндә
минем башка
Шундый уй килде әле,
Әллә, димен,
гөмбәләрнең
Яңгырмы әниләре?

ӘЙТМИМ

Әйт әле, әйт, Гайнетдин,
Әй, малай, әйт дим,
Этеңнең ничек исеме?
— Әйтмим.

Әйт инде, әйт, Гайнетдин,
Дуслар ич без, әйт дим,
Исеме ничек этеңнең?
— Әйтмим.

Гайнетдин шулай бик озак
Тинтерәтте бит мине.
Көчкә төшендем: ул этнең
«Әйтмим», имеш, исеме.

СЕРЛЕ БОЛЫТ

Бер ак болыт күгемнән
Китми дә китми—
Җиргә дә таммый, аны
Җилләр дә тетми.

Серләре бар шикелле
Нурлана һаман.
Төнлә шулай шатлыклы
Төш күрә сыман.

Әй, ак болыт, ак болыт,
Серецне белдем!
Куеныңнан кояш чыккач,
Үзең дә көлдең.

* * *

Әнисәнең туган көне,
Ул бу көнне туган.
Туган көнең була икән,
Әйбәт инде ул, туган!

Туган көнгә дусларыңны
Дәшүләре рәхәт.
Бу дөньяга тууларың,
Яшәүләрең рәхәт!

БИЯЛӘЙ

Безнең песи бияләен
Кигән килеш ашый.
Бияләен кигән килеш
Муеннарын кашый.
Ашап туйгач, бияләйле
Бармакларын ялый.
Чөнки песи бияләен
Бер дә сала алмый.

ҚОМ СӘГАТЕ

Сигезлегә охшап тора,
Баш-башта — ике төбе.
Бер мизгелме, бер секундмы
Қомының бер бөртеге?..

ЯҢГЫРНЫҢ ҚОЛАГЫ БАР

— Эссе!.. — диеп әлсерәде
Үләннәр һәм яфраклар.—
Эссе безгә, шундый эссе,
Қем килеп безне яклар?!
— Эссе!.. — диеп кабатлады
Қошлар да барсы бергә.
Әллә шуны ишеттеме —
Төште бит яңгыр җиргә!
Бигрәк мәрхәмәтле инде
Безнең якта яңгырлар.
Чакырсаң — тиз ишетәләр,
Минемчә, ул яңгырларның,
Мөгаен, колагы бар...

* * *

Әниемнең күзләре
Диңгез кебек тирән.
Ул күзләргә карасам,
Мин үземне күрәм.

Әниемнең карашы
Дулкын кебек назлы.
Чәчләремнән иркәли,
Иңнәремнән назлый.

Ә бүген соң?.. Ә бүген
Әниемнең карашы —
Әйтерсең төн карасы.

Әллә соң әниемнең
Зур кайгысы бармы?
Ничек итеп таратыйм
Кайгыларны?..

ТОМАН

Нәрсә ул шулай таралган
Ап-ак төтен сыман?
Хәлим миңа төшендерә:
— Нәрсә булсын, томан...

Аңладым! Кояш нурында
Томан шундый пешкән.
Җиләсрәк урын эзләп,
Безнең янга төшкән!..

ЧИШМӘ

Чишмә, чишмә, чишмәкәй,
Син — иң татлы чишмә лә!
Сулар ничек салкын була
Кайнап торган чишмәдә?!

ҠАЙТАВАЗ

Акбайга әйтәм:
— Өрмә! — дим.
(Аңлый үзе, күрәсең) —
Кайтавазга өрсәң,
димәк,
Үз-үзеңә өрәсең...

ҚҮЗЛЕК

Қара күзлек кидем дә мин,
Күрдегезме, кем булдым?!
Юк, мин беркем дә булмадым,
Ә менә көн — төн булды!

Қара,
      күзлек киюемә,
Төн җиткән, көн узган ич.
Йолдызлар гына күренми,
Шунысы бераз кызганыч!..

ҚҮЛӘГӘМ БЕЛӘН МИН

Рәхәтләнеп бер узыштык
Күләгәм белән.
Узышырга, әй, тырыштык
Күләгәм белән.
Ә аннан соң,
Су җылытып
Зур ләгән белән,
Чишенмичә коенуштык
Күләгәм белән.
Киемнәрем тәннәремә
Сыланган иде.
Күләгәм — коры,
                мин генә
Чыланган идем...

АЛМА

Кызарып пешкән алма бит —
Күр дә, өзеп алма!
Тешләп алган гына идем,
Чыжлап куйды алма.

Яратмады микән әллә
Болай эшләгәнне?
Хәер,
Кем яратсын инде үзен
Шулай тешләгәнне?!

* * *

Әллә соң рәссам булырга
Бу Кояш теләгәнме?
Кая барсам, нишләсәм дә,
Ясый ул күләгәмне.

Үзе шундый кыздыра ул,
Үзе шундый пешерә.
Каләме, буявы да юк —
Күләгәңне төшерә.

Агачларны да ясый ул,
Кирәксә — өебезне.
Күләгәбезне дә ясап
Ярата Кояш безне!..

БЕРЕНЧЕ БОЗ

Көне бик шыксыз бүген,— ди
Әби көрсенеп.—
Күктә кояш бер тапкыр да
Көлмәгән кебек...

Әле кояш кичә генә
Көлгән иде бит.
Инештә су коенырга
Килгән иде бит.

Уйнап арып, ул йокыга
Талганмы әллә?
Сизенмәстән, боз астында
Калганмы әллә?

* * *

Кичә миңа әни әйтте:
— Иртәгә — туган көнең!..
Иртүк тордым. Беркем дә юк.
Кайда соң туган көнем?

Идәннән дә эзләдем,
Түшәмнән дә эзләдем,
Сәке артыннан эзләдем —
Тик күрмәдем эзләрен.

Әни ярдәмгә ашыкты:
— Ни югалттың, балам? — ди.
— Туган көнне табыйк, әнием,
Юкса күрми калам! — дим.

Әни, көлеп,
тәрәзәне
Киереп ачып куйгач,
Зәңгәр күктән күзләремә
Карап елмайды Кояш.

Шунда аңладым бу көнне
Ничек бәйрәм итәсен,—
Миңа Кояш алып килгән
Туган көнем иртәсен!..

✦

ЭЧТӘЛЕК

Болытка хат. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 2
«ҚамАЗ» белән Алмаз. *Фаил Шәфигуллин тәрҗемәсе* . . . 2
Айдар. *Фаил Шәфигуллин тәрҗемәсе* 3
Яраталар. *Фаил Шәфигуллин тәрҗемәсе* 3
Әйтмим. *Фаил Шәфигуллин тәрҗемәсе* 4
Серле болыт. *Рәшит Әхмәтҗанов тәрҗемәсе* 4
...Әнисәнең туган көне. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 6
Бияләй. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 6
Ком сәгате. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 7
Янгырның колагы бар. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 7
...Әниемнең күзләре. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 8
Томан. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 8
Чишмә. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 9
Кайтаваз. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 9
Күзлек. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 10
Күләгәм белән мин. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 10
Алма. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 12
...Әллә соң рәссам булырга. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* . . . 12
Беренче боз. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 14
...Кичә миңа әни әйтте. *Нияз Акмалов тәрҗемәсе* 15

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга

Асылбаева Рина Михайловна

ПИСЬМО ТУЧКЕ

(на татарском языке, перевод с русского)

ИБ № 5999

Мөхәррире И. Зөлкарнәй, бизәлеш мөхәррире Ф. Хәсьянова, рәссамы И. Колмогорцева, техник мөхәррире Н. Зайнуллина, корректоры *С. Мифтахова.* Җыярга тапшырылды 22.10.90. Басарга кул куелды 1.03.91. Форматы $60\times90^{1}/_{16}$. Типогр. кәгазе № 1. Гарнитурасы «Литературная». Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 1, 0. Шартлы-буяу оттиск 3, 0. Нәшер-хисап табагы 1, 07. Тиражы 25 000 экз. Заказ Л-470. Бәясе 30 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19. Татарстан Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420111, Казань, Бауман ур., 19.

А $\frac{4803560202-068}{М\ 132(03)-91}$ 187—91

ББК 84(2Р-Тат)-5
А 90

ISBN 5—298—00805—4

© Татарстан китап нәшрияты, 1987
© Фаил Шәфигуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Нияз Акмалов тәрҗемәләре, 1991
© Ирина Колмогорцева рәсемнәре, 1991



30 тиен